**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
карары**

**№3211
23.05.2024**

Ел саен үткәрелә торган «Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» конкурсын үткәрү турында

Ата-аналарга яки аларны алмаштыручы затларга авыр тормыш хәлендә, социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганнарны тәрбияләүдә ярдәм күрсәтүче, балигъ булмаганнарның җәмгыятькә каршы гамәлләрен, алар тарафыннан җәмгыять өчен куркыныч булган гамәлләр, җинаятьләр кылуны яки кабатлауны кисәтү буенча балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактик эш алып баручы балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең абруен, статусын күтәрү максатында, Башкарма комитетның 2020 елның 30 октябрендәге 5733 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә ел саен үткәрелә торган «Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» конкурсын (алга таба - конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны үткәрүгә чыгымнарны финанслауны, 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына, кушымтада каралганча 50 000,00 (илле мең) сум 00 тиен күләмендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 23 маендагы
3211 номерлы карарына
1 нче кушымта

Ел саен үткәрелә торган «Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» конкурсын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» конкурсы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе инициативасы буенча Башкарма комитет тарафыннан үткәрелә, «Татарстан Республикасының иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе» Республика конкурсының шәһәр этабы булып тора. Конкурсны оештыручы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе тора.

2. Конкурс ата-аналарга яки аларны алмаштыручы затларга авыр тормыш хәлендә, социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганнарны тәрбияләүдә ярдәм күрсәтүче, балигъ булмаганнарның җәмгыятькә каршы гамәлләрен, алар тарафыннан җәмгыять өчен куркыныч булган гамәлләр, җинаятьләр кылуны яки кабатлауны кисәтү буенча балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактик эш алып баручы балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең абруен, статусын күтәрү максатында үткәрелә.

3. Конкурс балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, карауычысызлыгын һәм хокук бозуларын кисәтү һәм, гаиләне һәм балачакны яклау буенча конституцион нормаларны тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүгә булышлык итәргә юнәлдерелгән.

4. Конкурсның бурычлары:

1) балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренә ярдәм күрсәтү;

2) үз вәкаләтләре чикләрендә, балигъ булмаганнарга тәрбия һәм белем бирү буенча бурычларын үтәүдә ата-аналарга яки аларны алмаштыручы затларга ярдәм күрсәтергә тиешле тәрбия процессында катнашучыларның – балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең киләчәктәге эшен стимуллаштыру;

3) социаль куркыныч хәлдә яки авыр тормыш хәлендә калган балигъ булмаганнарны тәрбияләү өлкәсендә яңа методикаларны пропагандалау һәм тарату;

4) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының барлык органнарын һәм учреждениеләрен, хезмәт коллективларын, шулай ук балигъ булмаганнарның уку, эш яки яшәү урыны буенча иҗтимагый оешмаларны консолидацияләү.

5. Конкурста катнашучылар.

Конкурста балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре – балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең, хезмәт коллективларының вәкилләре, педагогик хезмәткәрләр, тренерлар, мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре катнашырга мөмкин. Катнашучылрның яше – 21 яшькә җиткән затлар.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

6. Конкурс агымдагы елның 1 апреленнән 31 маена кадәр 3 этапта үткәрелә:

1) беренче этап – 1 апрельдән 30 апрельгә кадәр конкурста катнашучыларның заявкаларын һәм материалларын Автозавод, Үзәк һәм Комсомол районнарының балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренә тапшыру;

2) икенче этап (читтән торып) – агымдагы елның 30 апреленнән 15 маена кадәр Автозавод, Үзәк һәм Комсомол районнарының балигъ булмаганнар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан конкурста катнашучыларны сайлап алу;

3) өченче этап (урынга барып) – агымдагы елның 15 маеннан 30 маена кадәр.

7. Конкурста катнашу өчен түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

1) форма буенча заявка (әлеге нигезләмәгә кушымта);

2) шәһәр конкурсында катнашучының портфолиосы.

8. Шәһәр этабын үткәрү йомгаклары турында мәгълүматны агымдагы елның 31 маена кадәр конкурсның зона этабының оештыру комитетына тапшырырга кирәк.

9. Оештыру комитетының составы Башкарма комитет карары белән раслана.

10. Муниципаль конкурсның эчтәлеге:

1) «Мин – балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячесе» визит карточкасы, аның дәвамында финалист җәмәгать тәрбиячеләре институтына, үзенең тәрбияләнүчеләренә һәм коллегаларына, гаиләгә карата мөнәсәбәтен, тормыш өстенлекләрен һәм үз эшенең нәтиҗәләрен ачып бирергә тиеш, регламент – 3 минут. Конкурсантның визит карточкасында сәхнәдә бер үк вакытта 4 тән артмаган кешенең катнашуы рөхсәт ителә.

Визит карточкасын бәяләү критерийлары (максималь 30 балл):

- тәкъдим ителгән тәҗрибәнең әйдәп баручы идеясе (максат ачык һәм конкрет итеп формалаштырылган, грамоталы нигезләнгән, реалистик һәм тәрбияләнүченең яшь үзенчәлекләренә туры килә, балигъ булмаганнарга карата төгәл һәм диагностикаланган) – 0 дән 5 баллга кадәр;

- тәрбия эшчәнлегенең эчтәлеген аргументлы аңлату (юнәлешләр, формалар, ысуллар куелган максатлардан чыгып сайланган; грамоталы нигезләнгән; тәрбия әһәмиятенә ия, системалы характерда; оригинальлек һәм авторлык алымы) – 0 дән 5 баллга кадәр;

- үз эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольдә тоту формаларын һәм алымнарын ачып бирү – 0 дән 5 баллга кадәр;

- алынган нәтиҗәләр (реаль; куелган максатларга адекват; аларны билгеләү ысуллары төгәл) – 0 дән 5 баллга кадәр;

- тәрбиячегә очраган проблемалар (грамоталы формалаштырылган; тәрбиячęнең үз эшчәнлеген анализлый һәм каршылыкларны, перспективаларны күрә белүе турында күзалларга мөмкинлек бирәләр) – 0 дән 5 баллга кадәр;

- регламентны үтәү – 0 дән 5 баллга кадәр;

2) балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә норматив-хокукый база нигезләрен белү предметына әңгәмә (максимум 50 балл);

- тапкырлык – 0 дән 10 баллга кадәр;

- фикерләү оригинальлеге – 0 дән 10 баллга кадәр;

- оештыру сәләте – 0 дән 10 баллга кадәр;

- иҗади якын килү – 0 дән 10 баллга кадәр;

- балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә законнарны белү – 0 дән 10 баллга кадәр.

3 бүлек. Конкурска йомгак ясау.

11. Оештыру комитетының конкурс йомгаклары турында карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Иң күп балл җыйган конкурсант конкурсның җиңүчесе дип таныла. Конкурста 2 нче, 3 нче урыннарны алган катнашучылар призерлар дип санала. Йомгаклар буенча 4-19 нчы урыннарны алган катнашучылар конкурс лауреатлары дип санала.

13. Конкурс җиңүчеләре, призерлары һәм лауреатлары дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнәләр.

14. Конкурсны үткәрү чыгымнарын финанслау Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Ел саен үткәрелә торган
«Балигъ булмаганнарның иң
яхшы җәмәгать тәрбиячесе»
конкурсы турында
нигезләмәгә кушымта

«Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе»
конкурсында катнашуга
заявка

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Конкурсатның Ф.И.А.и. (тулысынча) | |
| 2. | Туу датасы | |
| 3. | Эш урыны, вазыйфасы | |
| 4. | Эш урынының адресы, телефоны, электрон почтасы | |
| 5. | Өй адресы, телефоны, шәхси электрон почтасы | |
| 6. | Белеме турында мәгълүматлар | |
| 7. | Җәмәгать тәрбиячесе сыйфатында эш стажы | |
| 8. | Дәүләт һәм тармак бүләкләре | |
| 9. | Өстәмә рәвештә хәбәр итәргә кирәк дип санаган башка мәгълүматлар | |